ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 03.06.2026 г. Иннополис КАРАР 32

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»12.09.2025 ел, № 84 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 ел № 33-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законы, «Муниципаль милектәге җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 12.09.2025 ел, № 84 карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гомуми нигезләмәләрнең 1 бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 1.6, 1.7., 1.8., 1.9 пунктларын өстәргә:

«1.6. Ваклап сату Иннополис шәһәре Башкарма комитеты билгеләгән урыннарда гамәлгә ашырыла.

1.7. Ваклап сату һәм ваклап сату объектын урнаштыру, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән объектларны урнаштыруны җайга сала торган Иннополис шәһәре территориясендә расланган норматив хокукый актлар нигезендә хуҗалык итүче субъект тарафыннан ваклап сату объектын билгеләнгән урыннарда урнаштыруга вәкаләтле орган белән тиешле шартнамә төзелгән очракта, билгеләнгән урында рөхсәт ителгән дип санала.

1.8. Җирле үзидарә органы билгеләмәгән урыннарда һәм (яисә) тиешле шартнамәдән башка ваклап сату билгесез урында сәүдә итү дип таныла. Билгесез урыннарда сәүдә итүче затлар гамәлдәге законнар нигезендә административ җаваплылык тоталар.

1.9. Ваклап сатуны оештыруга килешү төзегән зат беркетелгән территориядә тиешле санитар халәтне тәэмин итәргә тиеш. Ваклап сатуны оештыру кирәкле документлар (лицензияләр, туры килү сертификатлары, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр, күрсәтелә торган хезмәтләр) нигезендә гамәлгә ашырыла.».

1.2. II бүлек. Төп төшенчәләргә һәм аларның билгеләмәләренә түбәндәге редакциядә м) пунктын өстәргә:

«м) ваклап сату объектлары - стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары, алар ярдәмендә ваклап (урамда) сәүдә башкарыла торган объектлар (лотоклар, тент палаткалары, зонтиклар, кәрзиннәр, күчереп йөртелә торган прилавкалар, кул арбалары һәм товарларны күрсәтү, күчереп йөртү һәм сату уңайлылыгы өчен башка җайланмалар);».

1.3. III бүлек. 3.1 пункт. Иннополис шәһәре территориясендә НТО урнаштыруга һәм тышкы күренешенә карата таләпләрне яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Ваклап сату һәм НТО урнаштыру НТО һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы белән расланган урыннарда Иннополис шәһәре территориясендә сезонлы НТО һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Я. Н.Елистратовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ф. Ханбиков